**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2022елның 27 декабре 3340 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетында Гражданнарны шәхси кабул итү көнен һәм вакытын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 декабрендәге 3291 номерлы карары нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетында вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү атна саен сишәмбе көнне 09:00 - 12:00 сәгатьләрдә үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Чернышевский ур., 23 й..

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарны шәхси кабул итү көнен һәм вакытын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге 4168 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетта эшләре белән идарә итүче В. Н. Воробьевка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**